**Тема: Начар гадәтләр. Наркомания- чорыбыз әфәте.**

**Максат:**

1. Укучыларны "Наркомания- чорыбыз әфәте" дигән темага уйланырга мәҗбүр итеп, тормышта аңа каршы тора белергә ярдәм итү.

2. Сәламәт яшәү күнекмәләре формалаштыру.

3. Укучыларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү.

4. Наркотик, наркомания турында төшенчә бирү.

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәсе:**

- Наркотикларның кеше организмына зыяны турында төшенү.
- Наркотикның гаиләгә китергән зыяны турында белү.
- Наркотикларны куллануга карата тискәре караш формалашу.
- Наркотикларны куллану- шайтан эшләреннән булган, Аллаһы Тәгалә кешеләрне тыйган пычрак эшләрдәндер икәнен аңлау.

**Эпиграф**

- ***«Еш очракта кеше үз- үзенең иң золымлы дошманы»*** *(Цицерон).*
- ***"Күп кешеләр ике әйбернең кадерең белмәсләр: беренчесе- сәламәтлек, икенчесе- буш вакыт"*** *(хәдис)*

**Дәреснең барышы**

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

- Гаҗиттән бер статьяны (ул- анда җибәрелгән бер атаның хатын) тыңлагыз, шуннан чыгып, бүгенге дәреснең темасын үзегез әйтеп бирегез:

*Безнең гаилә- гап- гади бер гаилә иде, ләкин 23 яшьтә булган улым аркасында бөтенесе дә үзгәрде. Тынычлык, шатлык китте бездән. Бер вакыт без, ата- аналар, эштә чакта малай өйгә иптәшләрен алып кайткан һәм алар аның сеңлесен, безнең 16 яшьлек кызыбызны, көчләгәннәр. Бәлки, ул да шунда катнашкандыр- аның турында кызымнан сорарга көчем җитмәде. Ник алай булган? Чөнки минем улым- наркоман. Аның бөтен яшәү максаты- наркотикка акча табып- исерүдә.*

*Ни эшләргә? Полиция: "Гаилә эшләренә катнашмыйбыз- үзегез хәл итегез",- диячәкне белеп, бөтен туганнарыбызны гаилә киңәшмәсенә чакырдык.*

*Һәм алар бер тавыштан:"Аны үтерергә кирәк,"- дигән карар чыгардылар.*

*Бер көнне ул шулай ук наркотиктан исереп кайтып, палас уртасына сузылып ятып йоклаганда, мин электророзеткага тимерчыбыкны тоташтырдым һәм үлем карарын тормышка үзем ашырдым. Аннары полициягa киттем...*

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

- Димәк, бүгенге дәреснең темасы... (Наркомания әфәте турында).

**III.Уку мәсьәләсен чишү.**

***1. Ситуациягә бәя бирү. "Ник ата кеше үз малаен, дөньяда иң кадерле кешеләрнең берсен, үтерелек дәрәҗәгә җиткән? - дигән сорауга җавап табу.***

- Ник ата кеше үз малаен, дөньяда иң кадерле кешеләрнең берсен, үтерелек дәрәҗәгә җиткән?

- Нәрсә ул наркотик?

***2. “Наркотик” һәм “наркомания” төшенчәләре нәрсәне аңлата?***

Наркотик – медицинада авыртуны басу, нерв системасын тынычландыру һәм йоклату өчен кулланыла торган, исертә, миңгерәүләтә торган матдә.
Наркомания- наркотиклар кулланудан барлыкка килгән авыру.
Наркомания – куркыныч чир.

- Наркомания – чорыбыз афәте. Россиядә ел саен наркоманиягә бәйле рәвештә 20 меңнән артык җинаять эшләнә.
- Соңгы 5 елда әйләнештән алынган наркотикларның гомуми күләме 16 тоннадан алып 95 тоннага җитте.

- Моңарчы без наркотикларны бәхетез гаиләләрдә туып – үскән үсмерләр генә куллана дигән фикер белән килешеп яшәдек. Кайбер ата – аналар: “Минем балам тәртипле, ул начар юлга басмас. Аның ашарына да, киярена дә, ялына да акчасы җитәрлек. Ул беркайчан да наркоман булмаячак, мин аны яхшы беләм,”- дип фикер йөртә. Ни аяныч, тормыш моның ялгыш фикер булуын раслап тора. Наркомания афәте һәркемнең ишеген теләсә кайсы вакытта шакырга мөмкин икән.

Иң беренче, наркомания афәтен булдырмас өчен, без аның ни дәрәҗәдә куркыныч булуын белеп торырга тиешбез.

***3. Наркотикның организмга тәэсире, аңа күнегү.***

- Наркотик организмга шулай тәэсир итә ки, ул һәрвакыт үзен искә төшерттереп тора. Әфьюн кулланган кеше бик аз вакытка гына (3- 10 минут) ирек, бәхет, мәхәббәт хисен тоям, дип аны куллана, ә аннары бу агу шәхеснең бөтен тормышын, киләчәген җимерә һәм чынлап та ул агу колына әверелә.

***4. Нәрсә ул “ломка организма”?***

- **Нарке –** грек сүзе. Хәрәкәтсез, хәтерсез дигәнне аңлата. Тамак бик нык кипкәндә, суны ничек эчәсең килсә, наркотикларга күнегү дә шулай була. Наркотик кулланмый тора икән кеше, организмда “ломка” башалана. “Ломка” (организмны сындыру) вакытында наркоманның гәүдәсе бөгәрләнә, сикергәли, буыннары түзә алмаслык авырта, эре – эре тир тамчылары бүленеп чыга. Авыру елый, сүгенә, кычкыра, кыргый тавышлар белән ярдәм сорый, чөңки наркоман андый вакытта йөрәгенең типкәнен, тырнагы,чәче үскәнен, канында, баш миендә булган бөтен күзәнәкләрнең хәрәкәтен көчле авыртуы итеп сизә һәм аңа чыдый алмый. Тагын наркотик кулланып бер- ничә минутка шушы авртуыннан котыласы килә. Ләкин наркотик инде аны очкындырмый.

***5. Наркотикның куркынычы.***

- Наркотикның куркынычы**-** аның сине беркайчан да үзеннән җибәрмәвендә.

Бер куллансаң- син аны колы.

***6. Эксперимент нәтиҗәсе: начар гадәтләр наркоманлыкка юл сала.***

- Сыра, аракы, шәраб, тәмәке дә - наркотиклар. Алар организмны наркотик матдәләргә күнектерә.
- Тикшеренүләр күрсәткәнчә, сыра яки шәраб, аракы эчү, тәмәке тарту, марихуана һәм башка наркотиклар куллану наркоманлыкка юл сала.
- Шуңа дәлил- кеше тәмәке тартуын, аракы өчүен бик зур көч куймыча, ташлый алмый.

***7. Наркотиклар куллана башлауга кешене нәрсә этәрә?***

- Социологик тикшерену мәгълүматларына караганда, зур шәһәрләрдә 16 яшькә кадәрге укучыларның 12 проценты бер тапкыр булса да наркотик татып караган. Наркотиклар куллана башлауга кешене нәрсә этәрә?

- Наркотикны сатучылар 1-2 мәртәбә аны бушка бирәләр: соңыннан син аларның коллары булып күп табыш китерәчәксең.
- Урамда, мәктәптә, дискотекада үсмерләргә жвачканы бушка таратып наркотикка күнектерәләр.
- “Дуслар”булып йөргән танышлар наркотикны бушка тәгъдим итәләр, чөнки яңа клиент өчен аларга бушлай бер наркотик “дозасын” бирәләр.

***8. Наркоманнарны ничек танырга мөмкин соң?***
- яшүсмернең кинәт кенә дуслары алышына;
- үз – үзен тотышы начарлана;
- хәтере югала;
- бәйләнешсез сөйли башлый;
- күңел төшенкелегенә бирелә;
- наркотиклар турында еш искә ала һ.б.

**9. Наркотиклар кешедә нинди авырулар китереп чыгара?**
- Баш мие, үпкә кан күзәнәкләрен тарката, эпилепсия кебек авырулар китереп чыгара. Баш авырту, аяк – кул мускулларында, эчәклек һәм ашказанында көчле авыртулар, күңел болгану, косу – наркоманнар дошманы. Яңа химик наркотиклар
кешенең кул, аяклар бозылуга китерә. Кеше төреләй чөреп ята.

***10. Наркоманнар нинди авырулар тараталар?***
- Наркоманнар венерик авырулар, вируслы –гепатит кебек чирләр тарата.
- Наркоманнарның күбесе СПИД белән авырый.

***11. Наркотик һәм закон.***
- Россиядә наркотиклар белән эш итү тыела. Россия Федерациясе Җинаять Кодексының “Халык сәламәтлегенә һәм җәмәгать әхлагына каршы кылынган җинаятьләр” дигән 25 нче бүлек бар. (*Укытучы 228, 230, 231нче маддәләр белән, укучыларны таныштыра)*

- Наркотикны кулланган өчен- полиция учётына кую, машинага “права” бирелмәү, яхшы эшкә урнашалмау.
- Наркотикны сатып алу, саклау өчен - иректән мәхрүм итү (төрмә) 3 елга кадәр.
- Наркотикны бүләк итү, сату өчен- 3-7 елга кадәр.

***12. Наркоманның язмышы.***
Наркоманлык – куркыныч чир, дидек. Һәм ул Россиядә зур тизлек белән тарала. Хәзер илдә наркоманнар саны **миллионнарча** исәпләнә. Чынбарлыкта бу сан шактый артыграк. Наркоманнарның күбесе наркология диспансерында исәптә тормый.
- Бер наркоман 60 лап яшүсмергә әлеге чирне “йоктыра”.
- Наркотик куллана башлауга 2 – 3 ай үтүгә, кеше әфьюнга тәмам ияләшеп җитә.
- Героинны куллана башлаган кеше 7 – 8 елдан, сирәк чакта 10 – 12 елдан үлемгә дучар була.
- Бу вакыт – (наркоман үлгәнче) аның үзе өчен дә, якын кешеләре өчен дә кайгы – хәсрәт, күз яшьләре чоры.
- Хәзергә наркоманнарны үтә нәтиҗәле дәвалау чаралары юк.

**IV. Әпиграф белән танышу.**
**-** Танылган шәхесләргә сүз бирик:
- ***«Еш очракта кеше үз- үзенең иң золымлы дошманы» (Цицерон).***

- Алдагы әйтемләрне ничек аңлыйсыз? Бу сүзләрне бүгенге дәреснең эпиграф итеп тактага яздык. Җөмләне хор белән кабатлыйк һәм үзебезнең йөрәкләребезгә гомер буена салыйк, беркайчанда онытмыйк. Хор белән укыйлар.

**V. Изге Коръән китабыннан.**

- Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримендә болай дип әйтте:

- ***«Әгәр синнән исерткеч һәм отыш уеннары хакында сорасалар, син: «Аларда зур гөнаһ һәм кешегә файдалары да бар, – дип әйт! Әмма файдасына караганда, гөнаһы, зарары күбрәк», – диген».*** (Бәкара: 219)

- Наркотик шулай ук кешене исертә торган нәрсә булгач, Аллаһы Тәгалә аны да тыйган. Ләкин, кызганыч, нәтиҗә көткәнчә булмады. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә Үзенең тәрбия ысулындагы катгый хөкемне үзен иманлыга санаган кешеләргә игълан итте:

- ***«Әй, сез, иман китергән бәндәләр! Әлбәттә, исертә торган нәрсәләр (моңа аракы да, тәмәке дә, наркотиклар да керәләр), отыш уеннары, сыннарга табыну һәм ырым, багучылык шөгыльләре шайтан эшләреннән булган пычрак эшләрдәндер, бу нәрсәләрдән ерак булыгыз шаять котылырсыз. Исерткечләр, отыш уеннары белән шайтан сезнең арагызга ачу, дошманлыкны салырга, шулар белән сезне Аллаһының зекереннән һәм намаз укудан тыярга тели. Кайчан инде бу эшләрдән туктыйсыз? Тыеласызмы инде, юкмы?»*** – дигән сорау белән Аллаһы Тәгалә әлеге аятен тәмамлый.

- Наркотик тәмәке, аракы куллануга караганда күпкә куркынычрак, чөнки ул кешене бик тиз арада үз колына әйләндерә һәм аны яшь вакытта ук юк итә. Кемнең картлыкка җиткән наркоманны күргәне бар? Күрә алмассыз: наркоман күптәт гүрдә ята. Аллаһы Тәгалә аңа биргән гомернең, саулыкның кадерен белмәгән һәм шуның өчен әле җавап бирәсе бар аңа.

**VI. Хәдис.**

- Мөхәммәд Пәйгамбәрнең хәдисен укып, аның турында үз фикерләрегезне әйтегез. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.с) әйтә:

- ***"Күп кешеләр ике әйбернең кадерең белмәсләр: беренчесе- сәламәтлек, икенчесе- буш вакыт".***

- Аракы, наркотик куллану- Аллаһы Тәгалә безгә әмәнәт итеп тапшырылган сәламәтлекнең, кире кайтарып булмый торган кыйммәтле вакытның кадерен белмәү була да инде.

**VII. Рефлексия (Йомгаклау).**

- Дәреснең темасын искә төшерегез.
- Бүген дәрестә мин шуны белдем..." дигән җөмләне дәвам итегез.
- "Наркотикларны куллану бик куркыныч, чөнки..." дигән сүзләрне тәмамлагыз.
- Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз? *(Наркотик кулланган кеше- "үзенең иң золымлы дошманы").*

**VIII. Өйгә эш:**

- "Наркотик кешене нәрсәләрдән мәхрүм итә?"- дигән сорауга җавап әзерләү (Бер сүз белән 10 мисал китерегез. Дәлилләгез). (Мисал итеп- ирекне, активлыкны, эшчәнлекне,саулыкны, матурлыкны, гәделлекне, гаиләне, дусларны, акылны, гомерне, чөнки...).

- Дәресне "Ашыгыч ярдәмдә" эшләгән врачының интернетта яшь үсмерләр өчен язган сүзләре белән тәмамлыйсым килә: *"Бүген чакыру буенчә бардык: 22 яшьлек егет үлгән иде. Гап- гади, чибәр, шундый яшь... Биртелеп тә, чирләп тә түгел. Ул "спайс" кына тарткан булган... Әгәрдә әнисенең кайгыдан ничек итеп кычкырганын ишетсәгез, бу агуга беркайчанда хәттә кагылмас идегез". (Спайс тәмәке шикелле тарта торган үлән: аңа химик наркотик кушыла. Спайсны тарткач кеше тилерә, котыра, күп очракта үлә. Узган елда Россияда аннан йөзләгән кеше үлгән).*